СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.08.2026 Баулы шәһәре №52

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы «Муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 декабрендәге 98 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 14 декабрендәге 98 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар «Коррупциягә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Контроль-хисап палатасы рәисе «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чыгымнарының туры килүен тикшереп тору

турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләрне тапшырырга тиеш, әлеге федераль законнарда билгеләнгән очракларда. Әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.»;

7 статьяның 6 пунктын түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«6. Контроль-хисап палатасының муниципаль вазыйфа биләүче вазыйфаи заты «Россия Федерациясе субъектларының, федераль территорияләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров